ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.07.2024 п.г.т. Алексеевское № 301

**Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 11.09.2017 ел, № 345 «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне раслау хакында» карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 10.05.2024 ел,№ 315 «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү,Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган Методикасына үзгәрешләр кертү турында», Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 14.08.2017 ел,№ 569 карары белән расланган «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләүгә Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары бюджетлары чыгымнары күләмен билгеләү,Татарстан Республикасында бюджетара мөнәсәбәтләр формалаштырганда исәпкә алына торган Методикасын раслау турында» карарларына туры китереп

**карар бирәм:**

1. Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының 11.09.2017 ел, № 345 «Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль берәмлек хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Гражданнар оборонасы, халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау, янгын куркынычсызлыгын һәм су объектларында кешеләрнең иминлеген тәэмин итү өлкәсендә муниципаль учреждениеләр хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәнең II бүлеген, «хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладлары» ның 1 нче таблицасын яңа редакциядә бәян итәргә:

Таблица 1

| № т/б | Хезмәткәрләр вазифалары | Вазифаи оклад, сум |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| 1 | Оешма җитәкчесе | 25 014,00 |
| 2 | Оператив дежурный | 19 242,00 |

2. Әлеге карар имзаланган вакыттан үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Алексеевск муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы рәисе Е. М. Мифтаховага йөкләргә.

**Башкарма комитет**
**җитәкчесе** **М.Р. Гайсин**